**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 85 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I) следующие изменения:

1) часть 12 статьи $11^2$ после слов «трудовую книжку» дополнить словами «(при наличии)»;

2) в статье 21:

а) в части 10 первое предложение изложить в следующей редакции: «В состав аттестационной комиссии включаются представитель нанимателя и (или) уполномоченные им государственные служащие (в том числе из подразделения по вопросам государственной службы и кадров и подразделения, в котором государственный служащий, подлежащий аттестации, замещает должность государственной службы), а также включаемые в состав аттестационной комиссии в соответствии с положениями части $10^2$ настоящей статьи независимые эксперты – представители научных, образовательных и других организаций, являющиеся специалистами в соответствующих областях и видах профессиональной служебной

деятельности государственных служащих, по вопросам кадровых технологий и государственной службы.»;

б) дополнить частями $10^2 - 10^4$ следующего содержания:

«$10^2$. Включаемые в состав аттестационных комиссий представители научных, образовательных и других организаций приглашаются и отбираются органом по управлению государственной службой по запросу представителя нанимателя, направленному без указания персональных данных независимых экспертов, в порядке, установленном указом Президента Республики Татарстан, принятым с учетом порядка, установленного Правительством Российской Федерации. Представители общественных советов, включаемые в состав аттестационных комиссий, определяются решениями соответствующих общественных советов.

$10^3$. Общий срок пребывания независимого эксперта в аттестационной комиссии государственного органа не может превышать три года. Исчисление данного срока осуществляется с момента первого включения независимого эксперта в состав аттестационной комиссии. Повторное включение данного независимого эксперта в состав аттестационной комиссии может быть осуществлено не ранее чем через три года после окончания срока пребывания в аттестационной комиссии.

$10^4$. Срок пребывания независимого эксперта в аттестационной и конкурсной комиссиях одного государственного органа не может превышать в совокупности три года.»;

3) в части 3 статьи 24:

а) в абзаце первом слово «отдельных» исключить;

б) пункт 1 после слов «на выплату» дополнить словами «в отдельных государственных органах»;

4) в статье 25:

а) часть 4 после слов «трудовую книжку» дополнить словами «(при наличии)»;

б) дополнить частями 6 – 9 следующего содержания:

«6. Государственным служащим, а также гражданам, уволенным с государственной службы после представления к награждению или поощрению в соответствии с частью 2 настоящей статьи, при награждении государственными наградами Республики Татарстан или поощрении Президентом Республики Татарстан, Председателем Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинетом Министров Республики Татарстан выплачивается единовременное поощрение за счет средств фонда оплаты труда государственных служащих.

7. В случае гибели (смерти) государственного служащего или смерти указанного в части 6 настоящей статьи гражданина, награжденных государственной наградой Республики Татарстан или поощренных Президентом Республики Татарстан, Председателем Государственного Совета Республики Татарстан, Кабинетом Министров Республики Татарстан, а также в случае награждения государственной наградой Республики Татарстан посмертно единовременное поощрение выплачивается членам семьи государственного служащего или гражданина. Выплата единовременного поощрения в таких случаях производится не

позднее чем через один месяц со дня истечения шестимесячного срока, в течение которого члены семьи погибшего (умершего) государственного служащего или умершего гражданина могут обратиться в государственный орган, в котором указанное лицо замещало должность, за выплатой единовременного поощрения. При этом указанный срок исчисляется со дня издания правового акта Республики Татарстан о награждении или поощрении таких государственного служащего или гражданина. При обращении нескольких членов семьи за единовременным поощрением, не полученным указанными государственным служащим или гражданином в связи с гибелью (смертью), сумма поощрения делится между членами семьи поровну.

8. Членами семьи, имеющими право на получение единовременного поощрения, предусмотренного частями 6 и 7 настоящей статьи, считаются:

1) супруга (супруг), состоявшая (состоявший) на день гибели (смерти) государственного служащего или смерти гражданина, уволенного с государственной службы, в браке с ним (с ней);

2) родители государственного служащего или гражданина, уволенного с государственной службы;

3) дети государственного служащего или гражданина, уволенного с государственной службы;

4) лица, находившиеся на иждивении погибшего (умершего) государственного служащего или умершего гражданина, уволенного с государственной службы.

9. Размеры и порядок выплаты единовременного поощрения государственным служащим и гражданам, уволенным с государственной службы, а также членам семей указанных лиц в случаях, предусмотренных частями $5^1$ и $5^2$ статьи 55 Федерального закона, частями 6 и 7 настоящей статьи, устанавливаются указом Президента Республики Татарстан с учетом положений Федерального закона.»;

5) в статье 33:

а) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Основными документами, подтверждающими стаж государственной службы, являются трудовая книжка установленного образца и (или) сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке.»;

б) часть 4 после слов «трудовой книжке» дополнить словами «и (или) сведениями о трудовой деятельности, оформленными в установленном законодательством порядке»;

6) пункт 4 части 1 статьи 41 дополнить словами «(при наличии), формирование сведений о трудовой деятельности за период прохождения государственной службы государственными служащими и представление указанных сведений в порядке, установленном законодательством Российской Федерации об индивидуальном (персонифицированном) учете в системе обязательного пенсионного страхования, для хранения в информационных ресурсах Пенсионного фонда Российской Федерации»;

7) статью 44 изложить в следующей редакции:

«Статья 44. **Развитие государственной службы**

1. Развитие государственной службы осуществляется в соответствии с основными направлениями ее развития, определяемыми указом Президента Республики Татарстан, государственными программами Республики Татарстан и с учетом основных направлений развития федеральной государственной гражданской службы, определяемых Президентом Российской Федерации.

2. Эксперименты по применению новых подходов к организации государственной службы и обеспечению деятельности государственных служащих могут проводиться в государственном органе, его самостоятельном структурном подразделении или территориальном органе либо в нескольких государственных органах (далее – эксперимент).

3. На период проведения эксперимента, но не более чем на один год, могут изменяться условия служебных контрактов государственных служащих – участников эксперимента. Изменение условий служебного контракта в этом случае осуществляется в порядке, установленном законодательством Российской Федерации, и не должно приводить к уменьшению размера денежного содержания государственного служащего – участника эксперимента по сравнению с его денежным содержанием на момент начала эксперимента, а также к понижению этого государственного служащего в должности по сравнению с должностью, замещаемой им на момент начала эксперимента.

4. Порядок организации и требования к проведению экспериментов, направленных на развитие государственной службы, устанавливаются указом Президента Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 17 (часть I), № 52 (часть I), № 55 (часть I), № 94 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 49 (часть I); 2020, № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I) следующие изменения:

1) часть 22 статьи 10 после слов «трудовую книжку» дополнить словами «(при наличии)»;

2) часть 4 статьи 15 изложить в следующей редакции:

«4. Муниципальный служащий, являющийся руководителем органа местного самоуправления, аппарата избирательной комиссии муниципального образования, заместитель указанного муниципального служащего в целях исключения конфликта интересов не могут представлять интересы муниципальных служащих в выборном

профсоюзном органе данного органа местного самоуправления, аппарата избирательной комиссии муниципального образования в период замещения ими соответствующей должности.»;

3) пункт 4 части 3 статьи 19 после слов «трудовую книжку» дополнить словами «и (или) сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке»;

4) в пункте 2 части 10 статьи 28 слова «копия трудовой книжки» заменить словами «сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке, и (или) копия трудовой книжки»;

5) в статье 30:

а) часть 2 изложить в следующей редакции:

«2. Основными документами, подтверждающими стаж муниципальной службы, являются трудовая книжка установленного образца и (или) сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке.»;

б) часть 4 после слов «трудовой книжке» дополнить словами «и (или) сведениями о трудовой деятельности, оформленными в установленном законодательством порядке»;

6) пункт 4 статьи 34 дополнить словами «(при наличии), формирование сведений о трудовой деятельности за период прохождения муниципальной службы муниципальными служащими и представление указанных сведений в порядке, установленном законодательством Российской Федерации об индивидуальном (персонифицированном) учете в системе обязательного пенсионного страхования, для хранения в информационных ресурсах Пенсионного фонда Российской Федерации»;

7) в пункте 4 части 11 статьи $34^1$ слова «копию трудовой книжки» заменить словами «сведения о трудовой деятельности, оформленные в установленном законодательством порядке, и (или) копию трудовой книжки».

**Статья 3**

Установить, что:

1) независимый эксперт, пребывающий в конкурсной и (или) аттестационной комиссии государственного органа более трех лет, сохраняет свои полномочия до истечения шести месяцев со дня вступления в силу настоящего Закона;

2) независимый эксперт, пребывающий на день вступления в силу настоящего Закона в конкурсной и (или) аттестационной комиссии государственного органа менее трех лет, сохраняет свои полномочия до истечения трех лет с момента его первого включения в состав соответствующей комиссии.

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
26 декабря 2020 года
№ 96-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $11^2$ статьяның 12 өлешенә «хезмәт кенәгәсенә» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2) 21 статьяда:
а) 10 өлештә беренче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аттестация комиссиясе составына яллаучы вәкиле һәм (яисә) ул вәкаләт тапшырган дәүләт хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсеннән һәм аттестацияләнергә тиешле дәүләт хезмәткәре дәүләт хезмәте вазыйфасын биләп торган бүлекчәдән), шулай ук әлеге статьяның $10^2$ өлеше нигезләмәләренә ярашлы рәвештә аттестация комиссиясе составына кертелә торган бәйсез экспертлар – дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә, кадрлар технологияләре һәм дәүләт хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә.»;
б) түбәндәге эчтәлекле $10^2$ – $10^4$ өлешләр өстәргә:

б) түбәндәге эчтәлекле $10^2 – 10^4$ өлешләр өстәргә:

«$10^2$. Аттестация комиссияләр составына кертелә торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртипне исәпкә алып кабул ителгән Татарстан Республикасы Президенты указында билгеләнгән тәртиптә, яллаучы вәкиленең бәйсез экспертлар персональ мәгълүматларын күрсәтмичә җибәрелгән соратуына нигезләнеп, дәүләт хезмәтенә идарә органы тарафыннан чакырыла һәм сайлап алына. Аттестация комиссияләре составына кертелә торган иҗтимагый советлар вәкилләре тиешле иҗтимагый советлар карарларында билгеләнә.

$10^3$. Дәүләт органының аттестация комиссиясендә бәйсез экспертның гомуми булу срогы өч елдан артык була алмый. Әлеге срокны исәпли башлау бәйсез экспертның аттестация комиссиясе составына беренче тапкыр кертелгән вакытыннан башкарыла. Әлеге бәйсез экспертны аттестация комиссиясе составына кабат кертү аттестация комиссиясендә булу срогы тәгәлләнгәннән соң кимендә өч ел узгач башкарыла ала.

$10^4$. Бәйсез экспертның бер дәүләт органының аттестация һәм конкурс комиссияләрендә булу срогы барысы бергә өч елдан артык була алмый.»;

3) 24 статьяның 3 өлешендә:

а) беренче абзацта «Аерым дәүләт» сүзләрен «Дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «арттырылган» сүзен «аерым дәүләт органнарында арттырылган» сүзләренә алмаштырырга;

4) 25 статьяда:

а) 4 өлешкә «хезмәт кенәгәсенә» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле 6 – 9 өлешләр өстәргә:

«6. Дәүләт хезмәткәрләренә, шулай ук әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә бүләкләүгә яисә кызыксындыру түләвенә тәкъдим ителгәннән соң дәүләт хезмәтеннән азат ителгән гражданнарга Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгәндә яисә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кызыксындыру түләве бирелгәндә дәүләт хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү фонды акчалары исәбеннән бер мәртәбәлек кызыксындыру түләве бирелә.

7. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән яисә Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кызыксындыру түләве бирелгән дәүләт хезмәткәре яисә әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән граждан һәлак булган (вафат булган) очракта, шулай ук вафат булганнан соң Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнгән очракта бер мәртәбәлек кызыксындыру түләве дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның гаилә әгъзаларына бирелә. Мондый очракларда бер мәртәбәлек кызыксындыру түләвен бирү һәлак булган (вафат булган) дәүләт хезмәткәренең яисә вафат булган гражданның гаилә

әгъзалары күрсәтелгән зат вазыйфа биләп торган дәүләт органына бер мәртәбәлек кызыксындыру түләвен бирүне сорап мөрәҗәгать итә алган алты айлык срок беткән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча башкарыла. Бу вакытта күрсәтелгән срок мондый дәүләт хезмәткәрен яисә гражданны бүләкләү яисә аңа кызыксындыру түләве бирү турында Татарстан Республикасы хокукый акты чыккан көннән башлап исәпләнә. Күрсәтелгән дәүләт хезмәткәре яисә граждан һәлак булу (вафат булу) сәбәпле алмыйча калган бер мәртәбәлек кызыксындыру түләвен бирүне сорап, берничә гаилә әгъзасы мөрәҗәгать иткәндә, кызыксындыру түләве суммасы гаилә әгъзалары арасында тигез бүленә.

8. Әлеге статьяның 6 һәм 7 өлешләрендә каралган бер мәртәбәлек кызыксындыру түләвен алу хокукына ия гаилә әгъзалары дип түбәндәгеләр санала:

1) дәүләт хезмәткәре һәлак булган (вафат булган) яисә дәүләт хезмәтеннән азат ителгән граждан вафат булган көнгә аның белән язылышкан хатыны (ире);

2) дәүләт хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәтеннән азат ителгән гражданның ата-анасы;

3) дәүләт хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәтеннән азат ителгән гражданның балалары;

4) һәлак булган (вафат булган) дәүләт хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәтеннән азат ителгән гражданның тәрбиясендә булган затлар.

9. Дәүләт хезмәткәренә һәм дәүләт хезмәтеннән азат ителгән гражданнарга, шулай ук Федераль законның 55 статьясындагы $5^1$ һәм $5^2$ өлешләрендә, әлеге статьяның 6 һәм 7 өлешләрендә каралган очракларда бер мәртәбәлек кызыксындыру түләве күләмнәре һәм аны бирү тәртибе, Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.»;

5) 33 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте стажын дәлилли торган төп документларны расланган үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр тәшкил итә.»;

б) 4 өлешкә «хезмәт кенәгәсендәге язулар» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

6) 41 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктына «хезмәт кенәгәләрен» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә, «алып бару» сүзләреннән соң «, дәүләт хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте узу чорында хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр туплау һәм күрсәтелгән белешмәләрне, Россия Федерациясе Пенсия фонды мәгълүмат ресурсларында саклау өчен, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру» сүзләрен өстәргә;

7) 44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«44 статья. **Дәүләт хезмәтен үстерү**

1. Дәүләт хезмәтен үстерү аның Татарстан Республикасы Президенты указында билгеләнә торган төп үсеш юнәлешләре, Татарстан Республикасы дәүләт программалары нигезендә һәм федераль дәүләт граждан хезмәтенең Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнә торган төп үсеш юнәлешләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт хезмәтен оештыруда һәм дәүләт хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итүдә яңа алымнар куллану буенча экспериментлар дәүләт органында, аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә яисә территориаль органында йә берничә дәүләт органында үткәрелергә мөмкин (алга таба – эксперимент).

3. Эксперимент үткәрү чорына, ләкин иң күбе бер елга, дәүләт хезмәткәрләренең – экспериментта катнашучыларның хезмәт контракты шартлары үзгәрергә мөмкин. Хезмәт контракты шартларының үзгәрүе бу очракта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә башкарыла һәм дәүләт хезмәткәренең – экспериментта катнашучының акчалата түләвенең, аның эксперимент башланган вакытка акчалата түләве белән чагыштырганда, кимүенә, шулай ук әлеге дәүләт хезмәткәре вазыйфасының, эксперимент башланган вакытта биләгән вазыйфасы белән чагыштырганда, түбәнәюенә китерергә тиеш түгел.

4. Дәүләт хезмәтен үстерүгә юнәлдерелгән экспериментлар үткәрүне оештыру тәртибе һәм аңа таләпләр Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 22 өлешендә «хезмәт киңәшчесенә» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булып торучы муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең урынбасары мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында тиешле вазыйфаларны биләү чорында әлеге җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының сайланулы һөнәри берлек органында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен белдерә алмый.»;

3) 19 статьяның 3 өлешендәге 4 пунктына «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләрне» сүзләрен өстәргә;

4) 28 статьяның 10 өлешендәге 2 пунктында «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 30 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәт стажын дәлилли торган төп документларны расланган үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр тәшкил итә.»;

б) 4 өлештә «хезмәт кенәгәсендәге язулар» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

6) 34 статьяның 4 пунктына «хезмәт кенәгәләрен» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә, «алып бару» сүзләреннән соң «, муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр туплау һәм күрсәтелгән белешмәләрне, Россия Федерациясе Пенсия фонды мәгълүмат ресурсларында саклау өчен, мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру» сүзләрен өстәргә;

7) 34[1] статьяның 11 өлешендәге 4 пунктында «хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсе күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) дәүләт органының конкурс һәм (яисә) аттестация комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып алты ай үткәнче саклап кала;

2) дәүләт органының конкурс һәм (яисә) аттестация комиссиясендә әлеге Закон үз көченә кергән көнгә өч елдан кимрәк булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен тиешле комиссия составына беренче мәртәбә кертелгән вакыттан алып өч ел үткәнче саклап кала.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 26 декабрь
№ 96-ТРЗ